ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

Большая Красная ур., 15/9, Казан ш., 420111

тән/факс. 8 (843) 222-02-77. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 59

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«06» 06 2024ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2023 елның 28 августындагы 107 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2023 елның 28 августындагы 107 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2023 елның 8 ноябрендәге 134 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлегендә:

3 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яисә җайга салу турында чикләмәләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәвен тәэмин итүдә, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законда, башка федераль законнарда коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларның үтәлешен (алга таба – хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу) тәэмин итүдә;»;

III бүлектә:

14 пунктны түбәндәге эчтәлектәге «е» пунктчасы белән тулыландырырга:

«е) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга комачаулаучы, аңа бәйле булмаган шартлар барлыкка килүе турында хәбәр итүе.»;

15.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15.4. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацта һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән белдерүләр коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы булган вазыйфаи зат тарафыннан карала, ул белдерүләрне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмә әзерли.»;

15.5 пунктта «14 пунктның «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән белдерү» сүзләрен «14 пунктның «б» пунктчасындагы бишенче абзацында һәм «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән белдерүләр» сүзләре белән алмаштырырга;

15.6 пунктта:

«а» пунктчасында «14 пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен «14 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алмаштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында, «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яисә хәбәрләмәләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 22, 23.3, 23.4, 24.1 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка төрле карарны кабул итү өчен киңәшләр.»;

16.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16.2. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән белдерүләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планга кертелгән) утырышында карала.»;

17 пунктта «14 пунктның «б» пунктчасы белән» сүзләрен «14 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

17.1 пунктның «а» пунктчасында «14 пунктның «б» пунктчасы белән» сүзләрен «14 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 23.4 пункт өстәргә:

«23.4. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча, һәм нигезләр булган очракта, комиссия әлеге Нигезләмәнең 20-23, 23.1-23.4 һәм 24.1 пунктларында каралганнан башкачарак карар кабул итә ала. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.».

Җитәкче А.В. Тыгин